# ЮЛЛАРЫГЫЗ ҺӘРЧАК ИМИН БУЛСЫН



Нәни дустым! Без, иртәнге йокыбыздан торып урамга чыгу белән, юл хәрәкәтенә катнашып китәбез. Ә урамда транспорт чараларының тыз да быз чабуына күз иярми. Машиналарларның төрләре, җәяүлеләрнең һәм пассажирларның саны елдан – ел арта, юл хәрәкәте көчәйгәннән көчәя. Юл транспорт һәлакәтләре (ЮТҺ) турында да ишетеп, күреп торабыз. Алар нәтиҗәсендә кешеләр һәлак була яисә җәрәхәтләнә, юл корылмалары җимерелә. Юл хәрәкә кагыдәләрен төгәл үтәсәң , игътибарлы һәм сак булсаң аянычлы хәлләргә юлыкаска да мөмкин. Моның өчен иң беренче чиратта юл хәрәкәте билгеләрен һәм кагыйдәләрен белергә кирәк.



Курыкмыйча, саклык белән юл аркылы чыгарга; урада дөрес юл сайларга; трамвай, троллейбус яисә автобуска ничек утырырга, анда үзеңне ничек тотарга кирәклеге турында сөйләшербез. Әле син, үскәч, бәлки, үзеңдә матур машина алырсың. Аны йөртер һәм бәлагә юлыкмас өчен дә юл хәрәкәте кагыйдәләрен белергә, үзеңне киләчәк тормышка хәзердән үк әзерләргә кирәк. Әлеге кагыйдәләрнең иң гадиләрен генә истә калдырыйк!!!

- Машина йөри торган юлда яки юл кырыеда беркайчанда уйнама;



# Велосипед белән машина юлына чыкма



# Урамны теләсә нинди урыннан аркылы чыкма!!!



Төркем белән барганда:

- Җәяүлеләр өчен булган кагыйдәләрнең барсында үтәгез;
- Өлкән озатучыларыгыз булсын

Юл хәрәкәтте кагыйдәләре махсус тамгалар – юл хәрәкәте билгеләре белән күрсәтелә. Алар бик күп без аларны ел буена өйрәнеп танышып китәрбез;

# Балалар


мәктәп
Кызыл белән каелган
Ак өчпочмак эчендә
Әй йөгерә ике бала
Каядыр бар көченә.
Бу билгене, билгеле,
Шофёрлар бик шәп
белә —
Аеруча сак булыгыз,
Юлдан балалар килә!

# Җәяүлеләр хәрәкәте тыела

Машиналар кызу бара,
Ерак түгел күк ара.
Тик, аягың атлаганчы,
Игътибар белән кара.
Юкмы менә бу билге:
Кызыл түгәрәк эчендә
Атлап бара җәяүле,
Тик ул сызылган инде.
Әгәр мондый билге
күрсәң,
Юлларга чыкма берүк.
Светофорлы чатлар эзлә,
Ә монысын урап үт.




# Велосипедларда йөрү тыела



Машина да тәгәрмәчле,
Тәгәрмәчле сәпит тә.
Шулай уйлап, балалар
(Йөрисе килгәч бик тә)
Олы юлга чыгалар да
Җилдерәләр сәпиттә.
Бу билгене күрсәләр,
Борылсыннар кирегә.
Ярамый шул
бу урында
Велосипедта йөрергә.
Кагыйдәне үтәмәсәң,
Мөмкин бәла килергә.


# Җәяүлеләр юлы



Бу юлдан атлап
баралар
Йә йөгерә, йә чабалар
Ак сакаллы
бабайлар,
Нәни шаян
малайлар,
Әбиләр һәм бәбиләр,
Өлкәннәр
һәм нәниләр.
Кызы белән әнисе,
Әтисе белән улы.
Әнә билге дә куелган,
«Бу, — дип, —
җәяүле юлы».

# Велосипед юлы

Мөгезеннән тотасың да
Утырасың, китәсең.
Кирәк җиргә бик тиз генә,
Ансат барып җитәсең.
Велосипед —
транспортның
Бик тә уңайлы төре.
Педалеңне әйләндер дә
Теләсә кайда йөре.
Болай уйлап ялгышма,
Алай гына түгел ул.
Зәңгәр түгәрәк эчендә
Ак велосипед көтеп торса,
Шушы булыр синең юл.




# Җәяүлеләренең юлны аркылы чыгу урыны




Ак, кара тасмалар буйлап
Җәяүле горур атлый.
Чөнки белә: шушы билге
Гомерен уяу саклый.
Әлеге билге кисәтә
Шофёрларны бу хакта:
— Игътибарлы булыгыз,—
ди, —
Җәяүле үткән чакта!


# Автомобиль юлы



Юлда йөрү бик җаваплы,
Сорый белем, игътибар.
Безгә ярдәмгә килергә
«Автомобиль юлы» дигән
Әле дә шушы билге бар.
Машина шул йөри алмый
Теләсә кай урыннан.
Хәрәкәт итә ул бары тик
Автомобиль юлыннан.

# Автобус яки трамвай тукталышы





Әгәр яратмыйсың икән
Өйдә генә ятарга,
Җыенгансың икән бүген
Кино йә театрга,
Бу билгене белү кирәк.
Аны белү мөһим бигрәк.
Утырып булмый
аннан башка
Трамвайга һәм автобуска.
Тукталышларда ул билге
Әверелә чып-чын дуска.

# Торак зона



Авыл, шәһәр, бистә аша
Үтсә әгәр юлыгыз,
Шушы билгене күрерсез —
Игътибарлы булыгыз.
Монда — торак зона, диеп,
Ул алдан ук искәртә.
Бәлагә тарымагыз, дип,
Һәр кешене кисәтә.

# Туклану пункты



Ашыйсы килгәнне каян
Белделәр, диясеңме,
Чәнечке белән пычакны
Ерактан күрәсеңме?
Ерак түгел кайнар чәйгә,
Тәмле аш һәм боткага,
Ачка үләм дигән чакта
Шушы билге коткара.




Олы юлда бик күп алар —
Мондый тамга-билгеләр.
Ерактан ук күренәләр,
Һәммәсе белсен, диләр.
Аларның изге уйлары —
Аларның изге эше.
Безне белсен, онытмасын,
Бәлаләргә юлыкмасын,
Исән-имин булсын, диләр,
Юлга чыккан һәр кеше!